ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_22.12.2021__ с. Муслюмово № _627_

**Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында**

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның балансслы туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, 29.12.2012 ел, № 273-ФЗ "Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 37 маддәсен үтәү йөзеннән, Россия Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 213н санлы, Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының "Белем бирү учреждениеләрендә укучыларның һәм тәрбияләнүчеләрнең туклануын оештыру буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында" 11.03.2012 ел, № 178 боерыгы нигезендә, «Дәүләт гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2021 елның 6 сентябрендәге 826 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүгә айлык һәм башка норматив чыгымнарны раслау хакында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 7 сентябрендәге 842 санлы «2022 елга айлык һәм башка төр түләүләр турында» карарына нигезләнеп, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында»гы карарын яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының “Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында" 2020 ел, 23 ноябрь, 576нчы карарын (2010 ел, 26 декабрь, 638нче карары төзәтмәләре белән) үз көчен югалткан дип санарга.

3. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

3.1. Мөслим муниципаль районы урта гомуми белем бирү мәктәпләре укучыларын ике тапкыр кайнар аш белән, башлангыч һәм төп гомуми белем бирү мәктәп укучыларын кайнар аш белән тәэмин итүне оештырырга;

3.2. Мөслим муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч белем бирү программалары буенча укучыларны 55 сум 55 тиенлек (илле биш сум 55 тиен) түләүсез кайнар аш белән тәэмин итәргә;
3.3. Мөслим муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны һәр уку көненә 8 сум 30 тиен субсидия өлеше һәм ата-ана түләве күләмендә тукландыруны оештырырга.

4. Түләү күләмен:

- урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен бер укучыга көненә 19 сум 20 тиен балансланган иртәнге аш, 5-11 сыйныф укучысына көненә 35 сум балансл төшке аш;

- төп гомуми белем бирү мәктәпләре өчен 5-9 сыйныф укучысына балансл төшке ашны көнгә 35 сум күләмендә билгеләргә.

5. Белем бирү учреждениесендә туклануны оештыру һәм түләү процессы белән бәйле операцияләрне башкару өчен автоматлаштырылган исәпкә алу системасын кулланырга AVSU.RU (AVSU.RU системасы) - ЭВМ һәм мәгълүмат базалары өчен Үзәк программа.

6. "ТР Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе" МКУ җитәкчесе Хәбибуллина Л. Я. га:

6.1. Укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүгә бүлеп бирелгән акчалардан максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

6.2. Иртәнге һәм төшке ашларның төп туклыклы матдәләр белән балансланган, витаминнар һәм микроэлементлар белән баетылган нормаларын һәм сыйфатын контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

6.3. Мәктәп яны участоклары продукциясе исәбенә мәктәп ашлары ассортиментын баету эшен көчәйтергә;

6.4. Гомуми белем бирү оешмаларына азык-төлекнең өзлексез килүен координацияләүне һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

7. Мәктәп укучыларын кайнар аш белән тәэмин итүче гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

7.1. Мәктәп ашханәләрен сыйфатлы азык-төлек белән өзлексез тәэмин итү.

7.2. Гамәлдәге санитар нормалар һәм кагыйдәләр нигезендә гомуми белем бирү учреждениеләрендә кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыруны контрольгә алырга.

8. Мөслим муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» МКУ (Н.А. Бубекова)нә гомуми белем бирү оешмаларының барлык укучылары өчен уку вакытында туклануны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тормышка ашырырга тәкъдим итәргә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **А.Р.Хуҗин**